**III ЧАКЫРЫЛЫШ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«СПАС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**L СЕССИЯ**

**КАРАР № 3**

Спас авылы 20 май 2019 ел

**«Татарстан Республикасы Бөгелмә**
**муниципаль районы «Спас авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегендә халык алдында тыңлаулар**
**(иҗтимагый фикер алышулар)**
**оештыру һәм үткәрү тәртибе турында»**
**Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның**
**14 февралендәге Спас авыл җирлеге**
**Советының XLIX сессиясенең**
**№3 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп

**Спас авыл җирлеге Советы**

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык алдында тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 февралендәге Спас авыл җирлеге Советының XLIX сессиясенең №3 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 4 бүлектә:

*- 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:*

«4. Халык алдында тыңлаулар халык, Бөгелмә муниципаль районының Спас авыл җирлеге Советы, Бөгелмә муниципаль районының «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы («Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча үткәрелә.

Спас авыл җирлеге советы яки халык инициативасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар Спас авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, ә «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы инициативасы буенча үткәрелүчесе («Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

җитәкчесе) – «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан.».

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**«Спас авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **А.В.Ишкова**